Республика Татарстан

**СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 57, д.Шарлиарема
423372
Телефон: 4-57-55

Татарстан Республикасы

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, йорт 57, Шәрләрәмә авылы
423372
Телефон: 4-57-55

ОГРН 1121651003671 ИНН/КПП 1636007010/163601001 ОКТМО 92653482


РЕШЕНИЕ КАРАР

**№ 78 2018 елның 7 ноябре**

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 23 апрелендәге 61 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 28 мартындагы 940 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 23 апрелендәге 61 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карарына үзгәреш кертергә.

1. 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Шәрләрәмә авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү чыгымнары елына айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә 6.72 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә.

2. 2018 елның 01 октябрендәге штат расписаниесен расларга һәм һәм яңадан исәпләп чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының сайланулы вазыйфаи Шарлиаремино авыл җирлегенең хезмәт өчен түләү нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 20 июнендәге 67 номерлы карарын юкка чыгарырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http:/ sarmanovo.tatarstan.ru адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
Советы рәисе Н.Н.Хуҗина